РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**14 апрель 2023 ел** **Чистай шәһәре** **№ 22/12**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
«Чистай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегенең
генераль планын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясы белән, 2023 елның 28 мартындагы гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып,Татарстан Республикасы «Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең кушымтада бирелгән Генераль планын расларга.
2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетына Россия Федерациясен территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планын урнаштырырга.
3. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Советының Законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль
районы Башлыгы Д.А. Иванов